**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Яту торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**28.11.2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 28.11.2024 елда үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча халык җыены беркетмәсе төзелде, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге Яту торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән, контракт буенча МХО зонасында хезмәт итүчеләр, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урам утлары төзелеше (Яту торак пунктында лампалар, энергия саклагыч светильниклар, электр товарлары сатып алу, урнаштыру, аларга агымдагы ремонт һәм карап тору, килешү буенча түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Иркәнәш торак пунтында сабантуй урынын җыештыру, скамейкалар, будка алу, урнаштыру, килешү буенча түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 43 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 29 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 29 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яту торак пунктында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.
2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге Яту торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган

гражданнардан, мобилизацияләнгән, контракт буенча МХО зонасында хезмәт итүчеләр, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урам утлары төзелеше (Яту торак пунктында лампалар, энергия саклагыч светильниклар, электр товарлары сатып алу, урнаштыру, аларга агымдагы ремонт һәм карап тору, килешү буенча түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Иркәнәш торак пунтында сабантуй урынын җыештыру, скамейкалар, будка алу, урнаштыру, килешү буенча түләү).

3. Җыенның нәтиҗәләрен Иркәнәш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән Минзәлә муниципаль районының сайтында бастырып чыгарырга (http://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән ун көн эчендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы

Камалов И. З.